ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2018 Казан ш. № 7-8/т

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә һәм саклауга тарифлар билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.13 статьясы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә һәм саклауга тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау һәм түләү срокларын билгеләү турында» 2016 елның 15 августындагы 1145/16 номерлы боерыгы, «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртү һәм саклау буенча хезмәтләр күрсәтүне башкаручыны сайлап алу буенча торглар оештыру һәм үткәрү, тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә һәм саклауга тарифлар билгеләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 28 июлендәге 611 номерлы карары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә һәм саклауга тарифларның нигез күрсәткечен билгеләү турында» 2017 елның 22 декабрендәге 7-9/т номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртү һәм саклау буенча хезмәтләр күрсәтүне башкаручыны сайлап алу буенча торгларның (бәя кимetү буенча аукционның) 2018 елның 4 сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә һәм саклауга тарифларны әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталарда каралган тарифларны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчергән һәм саклаган өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында» 2014 елның 12 сентябрендәге 7-17/т номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 7-8/т номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчереп йөртүгә тарифлар

| т/б № | Эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең атамасы | Тарифлар, сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | | 2019 елның 1 гыйнварфыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | | 2020 елның 1 гыйнварфыннан алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | |
| | | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән |
| 1. | Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү, бер транспорт чарасын күчереп йөрткән өчен, шул исәптән: | 1 925,42 | 2 272,00 | 2 006,29 | 2 407,55 | 2 078,52 | 2 494,22 |
| 1.1 | төяү-бушату эшләре | 561,02 | 662,00 | 584,58 | 701,50 | 605,62 | 726,74 |

Искәрмә.

Төяү-бушату эшләре өчен түләү транспорт чарасын махсуслаштырылган транспорт чарасына төягәннән соң һәм аны махсуслаштырылган урынга саклау өчен урнаштырганчы аны тоткарлау сәбәбе бетерелгән очракта алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 7-8/т номерлы карарына <u>2 нче кушымта</u>

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын саклауга тарифлар

| т/б № | Эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең атамасы | Тарифлар, сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | | 2019 елның 1 гыйнварфыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | | 2020 елның 1 гыйнварфыннан алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | |
| | | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән | НДСны исәпкә алмыйча | НДС белән |
| 1. | Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урында саклау, бер урын өчен бер сәгатькә, шул исәптән: | | | | | | |
| 1.1 | A, A1, M, B1 категорияләре | 22,23 | 26,23 | 23,16 | 27,79 | 23,99 | 28,79 |
| 1.2 | B, D1, C1 категорияләре | 44,46 | 52,46 | 46,33 | 55,60 | 48,00 | 57,60 |
| 1.3 | C, D, BE, C1E, D1E категорияләре | 88,92 | 104,93 | 92,65 | 111,18 | 95,99 | 115,19 |
| 1.4 | CE, DE категорияләре | 111,19 | 131,20 | 115,86 | 139,03 | 120,03 | 144,04 |
| 1.5 | зур булмаган транспорт чаралары | 133,38 | 157,39 | 138,98 | 166,78 | 143,98 | 172,78 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге